# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“23” ноябрь 2020 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 23 ноябрендә «Сез 2021 елда Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Авыл янындагы “Бәйкә” чишмәсен төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу, ремонтлау, канауны тирәнәйтү, транспорт чыгымнары һәм хезмәт өчен түләү;

- авыл территориясен чистарту һәм хезмәт өчен түләү.

2) Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

-лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу,урнаштыру һәм хезмәтләр өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 110 (бер йөз ун) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 58 (илле сигез) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 58(илле сигез) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2021 елда Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Авыл янындагы “Бәйкә” чишмәсен төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу, ремонтлау, канауны тирәнәйтү, транспорт чыгымнары һәм хезмәт өчен түләү;

- авыл территориясен чистарту һәм хезмәт өчен түләү.

2) Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

-лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу,урнаштыру һәм хезмәтләр өчен түләү;

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Салахов И.И.